| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СУГУШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «СУГЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

2020 елның 31 гыйнварендәге № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск
муниципаль районының «Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр
күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә
торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм естәмәләр исәпкә алып), «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1, 2 нче кушымта нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк ур.,27 й. мәгълүмат стендында игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2019 елның 13 мартындагы 7 номерлы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының карарын үз кечен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
" Сугышлы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.К. Янгирова

«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль
районының «Ивановка авыл җирлеге»ндә 2020 елның 1 февраленнән күмү буенча
хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 320 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1 160 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 2 644,86 |
| Барлыгы | 6 124,86 |

«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль
районының «Сугышлы авыл җирлеге»ндә 2020 елның 1 февраленнән күмү буенча
хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 577 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 743 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1 160 |
| 5. Кабер казу һәм күмү | 2 644,86 |
| Барлыгы | 6 124,86 |